МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2016 г.Казань № 12/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
2015 елның 30 сентябрендәге
“Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында
җитен комплексын үстерү” төбәк программасын
раслау турында” № 228/2-пр боерыгына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 13 апрелендәге “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисади әһәмиятле төбәк программаларын сайлап алу тәртибен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге № 1042 карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисади әһәмиятле төбәк программаларына теләктәшлек күрсәтү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрендә каралган документларның рәвешләрен раслау турында” № 134 боерыгын үтәү максатында **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2015 елның 30 сентябрендәге “Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын раслау турында” № 228/2-пр боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка карата 1 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.2. Боерыкка карата 2 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.3. Боерыкка карата 3 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.4. Боерыкка карата 4 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә

| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.02.2016 г.Казань № 12/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы
һәм азык-төлек министрлыгының
2015 елның 30 сентябрендәге
“Ведомстvoның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында
җитен комплексын үстерү” төбәк программасын
раслау турында” № 228/2-пр боерыгына
үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 13 апрелендәге “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисади әһәмиятле төбәк программаларын сайлап алу тәртибен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге № 1042 карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыгын үстерү буенча икътисади әһәмиятле төбәк программаларына теләктәшлек күрсәтү өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрендә каралган документларның рәвешләрен раслау турында” № 134 боерыгын үтәү максатында **боерык бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2015 елның 30 сентябрендәге “Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын раслау турында” № 228/2-пр боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка карата 1 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.2. Боерыкка карата 2 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.3. Боерыкка карата 3 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.4. Боерыкка карата 4 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә);

1.5. Боерыкка карата 5 кушымтаны яңа эчтәлегендә бәян итәргә (теркәлә).

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Н.Л. Титовны җаваплы итеп билгеләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
30.09.2015 № 228/2-пр боерыгына
(ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
10.02.2016 № 12/2-пр боерыгы
төзәтмәсендә) 1 кушымта

# ВЕДОМСТВОНЫҢ МАКСАТЧАН ИКЪТИСАДИ ӘҺӘМИЯТЛЕ “2015-2016 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА ҖИТЕН КОМПЛЕКСЫН ҮСТЕРҮ” ТОБӘК ПРОГРАММАСЫ

## ЭЧТӘЛЕК

1. Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасының паспорты...3

2. Программа хәл итәргә тиешле проблемаларга сыйфатлама...5

3. Җитен тармагының агымдагы торышына анализ...6

4. Программаның максатлары һәм бурычлары...8

5. Программадан көтелә торган һәм ахыргы нәтиҗәләр һәм максатчан индикаторлар...8

6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы...10

7. Программаны үтәү вакытлары...10

8. Программаны үтәүнең соңиаль, икътисади нәтиҗәләренә тасвирлама, максатка ирешүдә Программа керткән өлешкә гомуми бәяләмә...11

9. Бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген бәяләү...11

10. Программаны ресурслар белән тәэмин итү үзенчәлекләре...12

11. Программаның үтәлеше белән идарә итү системасын тасвирлау...13

12. Программаның үтәлеш куркынычларын бәяләү...14

| | |
|---|---|
| Программаның аталышы | Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасы |
| Программаны эшләү өчен нигезләр | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге “2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерүнең һәм авыл хуҗалыгы продуктлары, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы турында” № 717 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктлары, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасын раслау турында” 08.04.2013 № 235 карары. |
| Программаның заказчысы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның төп эшләүчеләре | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Программаның максаты | Үзебезнең илдәге чимал базасын булдыру һәм үзебезнең илдә җитештерелгән җитен продуктларын арттыру |
| Төп бурычлар | 1 бурыч. Җитен җепселен тулай җыеп алуны арттыру.<br>2 бурыч. Сүсле җитенне тулай җыеп алуны арттыру.<br>3 бурыч. Җитен җепселен эшләп чыгаруны арттыру. |
| Программада катнашучылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Программаның төп чаралары | 1. Җитенне беренчел эшкәртү объектларын үзгәртеп коруны, техник яктан яңадан коралландыруны һәм модернизацияләүне исәпкә алып, төзелеш өчен ныклы сарыфлар.<br>2. Россия Федерациясенең эчке базарында җитен, киндер һәм сүскә күчергәндә башка сүсле культураларны сатучы товар җитештерүчеләргә җитен (сүс яки май җитенен), киндер һәм башка сүс культураларын җитештерүгә чыгымнарның бер өлешен субсидияләү. |
| Программаны үтәү вакытлары һәм этаплары | 2015-2016 еллар |
| Программаны башкаручылар | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының авыл хуҗалыгы предприятиеләре. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Барлыгы – 122,0 миллион сум (алга таба млн сум), шул исәптән, төбәк бюджеты – 23,0 млн сум;<br>бюджетныкы булмаган чыганаклар – 99,0 млн сум.<br><br>2015 ел – 87,0 млн сум, шул исәптән,<br>төбәк бюджеты – 20,0 млн сум;<br>бюджетныкы булмаган чыганаклар – 67,0 млн сум.<br><br>2016 ел – 35,0 млн сум, шул исәптән,<br>төбәк бюджеты – 3,0 млн сум;<br>бюджетныкы булмаган чыганаклар – 32,0 млн сум |
| Программаның максатчан индикаторлары һәм | 1. Җитен җепселен тулай җыеп алуны 0,94 мең тоннага арттыру (алга таба – мең тонна);<br>2. Сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алуны 0,06 мең |

| | |
|---|---|
| программа күрсәткечләре (2013 елга карата 2016 ел) | тоннага арттыру;<br>3. Сүсле җитеннән уңыш алуны бер гектарга 0,5 центнерга арттыру (алга таба – ц/га);<br>4. Чәчүлек мәйданын 600 гектарга (алга таба – га) арттыру;<br>5. Җитен җепселен эшләп чыгаруны 790 тоннага арттыру. |
| Программаны үтәүдән көтелгән нәтиҗәләр (2016 елда) | 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу 0,94 мең тоннага кадәр;<br>2. Сүс җитене орлыкларын тулай җыеп алуны 0,11 мең тоннага кадәр;<br>3. Сүсле җитеннән уңыш алу дәрәҗәсе 13,7 ц/га;<br>4. Чәчүлек мәйданы 1,1 мең гектарга кадәр (алга таба – мең га);<br>5. Җитен җепселен эшләп чыгару 1,42 мең тоннага кадәр. |
| Идарә һәм контрольлек итү системасы | Программаны үтәү буенча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба – Министрлык) игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы булып тора. |

## 2. Программа хәл итәргә тиешле проблемаларга сыйфатлама

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасы (алга таба – Программа) җитен җитештерү тармагын тотрыклы үстерү инструментына әверелергә тиеш, бу исә Татарстан Республикасында агросәнәгать комплексын үстерүнең өстенлекле максатларына ирешүнең бер өлеше булып тора.

Программа “2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктлары, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” дәүләт программасы кысаларында әзерләнде.

Илдәге җитен чәчә торган төбәкләрдә тулай продуктның зур өлешен тукыма һәм җиңел сәнәгать продуктлары тәшкил итә. Безнең илдә һәм дөньяда табигый сүстән, аеруча җитеннән ясалган тукымаларга ихтыяҗның даими артуы, аннан файдалануның кабатланмас үзенчәлекләре аркасында, мантыйкый ки, тукыма сәнәгатен үстерүне һәм модернизацияләүне тизләтүне таләп итә. Бу исә, үз чиратында, җитен җепселен җитештерүне арттыру өчен стимул бирәчәк. Россиядә җитен комплексын үстерүдә чын-чын ихтыяҗ килеп туа, бу исә ил икътисадының тукыма, химия, азык-төлек, фармацевтика, медицина, оборона тармаклары өчен ышанычлы, үзебезнең илдә җитештерелгән чимал базасын булдыруга ярдәм итәчәк.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү стратегиясе, җитештерүне үстерү темпларын арттыру, аның эчке кулланудагы күләмнәрен озак вакытка үстерү шарты белән, өстәмә җитен продуктларын үстерү, шулай ук импорт-алмаш (мамык чималы импортын кыскарту) хисабына тәэмин ителә ала.

Җитен комплексын тотрыклы үстерү өчен булган потенциалны уңышлы тормышка ашыру өчен төп каршылык булып тармакның техник яктан тәэмин ителеш дәрәҗәсенең түбән булуы тора.

Җитен комплексын үстерүнең төп факторы булып җитештерүгә инновацияле технологияләрне кертү тора. Заманча технологияләрдән файдалану продуктның сыйфатын дөнья стандартлары дәрәҗәсендә тәэмин итәчәк, җитеннән яңа төрле, бигрәк тә икътисадның башка тармакларында сорала торган продуктларны алу мөмкинлеген бирәчәк. Шушы юнәлештә заманча фәнни эшләнмәләрнең булмавы җитен комплексын үстерүнең инновацияле процессын тоткарлап тора.

Нәтиҗәдә җитен җитештерүне үстерүдә “йомык бөҗра” барлыкка килә: үсеш өчен ресурсларның җитеп бетмәве аркасында технологик яктан артта калына, бу исә продуктның түбән сыйфаты белән аңлатыла һәм җитештерүдә зур чыгымнарга китерә, импорт белән чагыштырганда аның көндәшлек сәләтен киметә. Шушы шартларда тармакның инвестиция ягыннан үзенә җәлеп итү дәрәҗәсе шулай ук түбән булып чыга, бу аны үстерү өчен ресурсларны җәлеп итү мөмкинлекләрен кисәк чикли.

“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” программасы аталган проблемаларны хәл итү өчен юнәлдерелә дә инде.

## 3. Җитен тармагының агымдагы торышына анализ

Сүсле җитен – Россиядә тукыма сәнәгате өчен чимал бирә торган бердәнбер авыл хуҗалыгы культурасы. Сүсле җитен бик югары агротехник әһәмияткә ия, чәчүлек әйләнешенең продуктлылылыгын тулаем алганда арттырып, ул күп кенә авыл хуҗалыгы культуралары өчен кыйммәтле элгәр булып тора. Сүсле җитеннең биологик үзенчәлекләре аның туфрак-климат шартларына: уңай температураларның суммасына, яуган явым-төшеп күләменә, туфракларның тибына карата үзенчәлекле таләпләре белән билгеләнә. Сүсле җитеннең вегетация чоры 70 көннән алып 90 көнгә кадәр тәшкил итә, ә уңай температураларның суммасы 18 градустан югары булганда 700 алып 1227 градуска кадәр тәшкил итәргә тиеш. Әлеге параметрлар аның Россия территориясендә урнашуын билгели.

Сүсле җитен эшкәртү өчен югары дәрәҗәле матди-техник чыгымнар таләп итә торган интенсив игенчелек культурасы булып санала, әлеге чыгымнар бөртекле культураларны үстерүгә караганда 3-5 мәртәбә артык, шул ук вакытта ресурсларның гомуми күләменнән 1/3 өлешен уңыш алганчыга кадәр бер ел алдан тотарга кирәк һәм ел саен ягулык-майлау материалларына, минерал ашламаларга һәм үсемлекләрне яклау буенча химик чараларга бәяләр арту аркасында аны җитештерүнең үзкыйммәте дә арта.

Сүсле җитенне Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексы оешмалары кырларында үстерү игенчелек культураларының гомуми күтәрелешенә, чәчүлек әйләнешендәге барлык культураларның уңышын арттыруга ярдәм итә. Асылда, югары уңышларны сабан культуралары бирә, алар чәчүлек әйләнешендә турыдан-туры сүсле җитеннән соң килә. Бу сүсле

житеннән соң туфракның чүп үләннәреннән чистарып һәм туклыклы матдәләргә баеп калуы белән аңлатыла.

Сүсле житенне үстерүдә төп проблемаларның берсе бүгенге көндә техника кытлыгыннан гыйбарәт. Чәчү һәм җыеп алу вакытларын бозу аркасында авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре уңыш алуда күп югалтулар кичерә. Сүсле җитенне җыеп алгандагы төп югалтулар башка авыл хуҗалыгы культуралары белән чагыштырмача күбрәк. Өстәмә җитен җыю техникасын сатып алу зарурлыгы бар.

**01.01.2015 карата АСК җитен тармагы предприятиеләрендә сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының, технологик җайланмаларның искерү дәрәҗәсен анализлау**

**1 таблица**

| Җитен орлыгы станцияләре | | Җитен заводлары | |
|---|---|---|---|
| Яше | Гомуми нәтиҗәгә карата җайланма, процентларда | Яше | Гомуми нәтиҗәгә карата җайланма, процентларда |
| 10 елга кадәр | - | 10 елга кадәр | 100 |
| 10 алып 20 кадәр | - | 10 алып 20 кадәр | |
| 20 елдан артык | - | 20 елдан артык | |

**01.01.2015 карата җитен чәчә торган хуҗалыкларда сүсле җитенне үстерү һәм җыеп алу буенча махсус авыл хуҗалыгы машиналарының искерү дәрәҗәсен анализлау**

**2 таблица**

| Техниканың аталышы | Эксплуатацияләүдә 8 елдан артык булган техниканың булуы, гомуми санынннан проңентларда |
|---|---|
| Катнаш чәчү машинасы (СКЛ-3,6) | 100 |
| Җитен җыю комбайны | 70 |
| Җитен йолку машинасы | 50 |
| Җитен тасмаларын әйләндергеч | 70 |
| Тыгызлагыч-төргәккә җыйгыч | 50 |
| Алгыч-тарап чистарткыч | 100 |
| Җитен тасмаларын суткеч | юк |
| Өлешләргә бүлгеч | юк |
| Төргәкләрне төягеч | 50 |
| Җитен өемнәрен киптергеч | юк |
| Җитен өемнәрен сугу машинасы | юк |
| Орлык чистарткыч машина | юк |

## 4. Программаның максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты – чимал базасын арттыру һәм үзебезнең илдә җитен продуктлары җитештерү.

Куелган максатка ирешү киләчәктә тулы, нәтиҗәле үсә торган җитен комплексы булдыру өчен ышанычлы нигез тәшкил итәчәк.

Программа максатына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

җитен җепселен тулай җыеп алуны 0,94 мең тоннага арттыру;

сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алуны 0,06 мең тоннага арттыру;

сүсле җитеннән уңыш алуны бер гектарга 0,5 центнерга арттыру;

чәчүлек мәйданын 600 гектарга (алга таба – га) арттыру;

җитен җепселен эшләп чыгаруны 790 тоннага арттыру.

## 5. Программадан көтелә торган һәм ахыргы нәтиҗәләр һәм максатчан индикаторлар

Программаның максатына ирешү чыгарыла торган продуктларның физик күләмен арттыру һәм технологик чылбырның барлык стадияләрендә җитештерү нәтиҗәлелеген арттыру шарты белән мөмкин.

Программаның үтәлеш нәтиҗәсе сан күрсәткечләре белән билгеләнә, алар объективлык, дөреслек, үтәкүренмәлелек, чагыштырмалылык критерийларына җавап бирә.

Программаның елларга бүленгән максатчан индикаторлары 3 таблицада чагылдырылды.

Программаның максатчан индикаторлары 4 таблицада.

### 2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү

**3 таблица**

| Индикаторның аталышы | Үлчәү берәмлеге | Индикаторларның (күрсәткечләрнең) мәгънәсе | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу | мең тонна | 0,66 | 1,3 | 1,5 | 1,6 |
| 2. Сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алу | мең тонна | 0,05 | 0,09 | 0,1 | 0,11 |
| 3. Сүсле җитен уңышы | ц/га | 13,2 | 13,5 | 13,6 | 13,7 |
| 4. Чәчүлек мәйданы | га | 500 | 860 | 1000 | 1100 |
| 5. Сүсле җитен эшләп чыгару | тонна | 630 | 1100 | 1320 | 1420 |

## Программаны үтәү чорына җитен комплексы продуктларын җитештерүнең үсеш алу темплары

**4 таблица**

| Индикаторның аталышы | Җитен җитештерү продуктларын җитештерүнең үсеш алу темплары, алдагы елга карата процентларда | | |
|---|---|---|---|
| | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел |
| 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу | 197 | 115 | 107 |
| 2. Сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алу | 180 | 111 | 110 |
| 3. Сүсле җитен уңышы | 102 | 101 | 101 |
| 4. Чәчүлек мәйданы | 172 | 116 | 110 |
| 5. Сүсле җитен эшләп чыгару | 174 | 120 | 108 |

## Программаны үтәү еллары буенча табигый мәгънәсендә алдагы 3 елга күрсәткечләрнең уртача мәгънәсенә карата җитештерүнең үсеш алуы

**5 таблица**

| Индикаторның аталышы | Үлчәү берәмлеге | 3 елга уртача күрсәткечләр (2011-2013 еллар) | Үсеш алу | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3 ел очен уртача күрсәткечкә карата 2014 ел | 3 ел өчен уртача күрсәткечкә карата 2015 ел | 3 ел өчен уртача күрсәткечкә карата 2016 ел |
| 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу | мең тонна | 0,88 | 0,42 | 0,62 | 0,72 |
| 2. Сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алу | мең тонна | 0,07 | 0,02 | 0,03 | 0,04 |
| 3. Сүсле җитен уцышы | ц/га | 11,9 | 1,3 | 1,6 | 1,8 |
| 4. Чәчүлек мәйданы | га | 740 | 120 | 260 | 360 |
| 5. Сүсле җитен эшләп чыгару | тонна | 780 | 320 | 540 | 640 |

## Программаны үтәү еллары буенча процентларда алдагы 3 елга күрсәткечләрнең уртача мәгънәсенә карата җитештерүнең үсеш алуы

**6 таблица**

| Индикаторның аталышы | Үлчәү берәмлеге | 3 елга уртача күрсәткечләр | Үсеш алу | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | 3 ел өчен | 3 ел өчен | 3 ел өчен |

| | | (2011-2013 еллар) | уртача күрсәткечкә карата 2014 ел | уртача күрсәткечкә карата 2015 ел | уртача күрсәткечкә карата 2016 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу | мең тонна | 0,88 | 147 | 170 | 182 |
| 2. Сүсле җитен орлыкларын тулай җыеп алу | мең тонна | 0,07 | 128 | 142 | 157 |
| 3. Сүсле җитен уңышы | ц/га | 11,9 | 113 | 114 | 115 |
| 4. Чәчүлек мәйданы | га | 740 | 116 | 135 | 149 |
| 5. Сүсле җитен эшләп чыгару | тонна | 780 | 141 | 169 | 182 |

## 6. Программа чараларының исемлеге һәм тасвирламасы

Татарстан Республикасында сүсле җитенне утырту, үстерү һәм җыеп алу белән җитен чәчүче хуҗалыклар шөгыльләнә. Сүсле җитенне җитештерү, үстерү продуктлары булып сүскә күчергәндә талкынмаган җитен, җитен саламы һәм сүсле җитен орлыклары тора.

Җитен үстерү зур чыгымнар таләп итә. Бу туфракны махсуслаштырылган техника белән эшкәртү, аерым ашлама торен һәм гирбицидлар куллану белән аңлатыла. Шулай ук җитенне җыеп алу очен махсуслаштырылган кыйммәтле комбайннар таләп ителә.

Сүскә күчергәндә җитен сатучы товар җитештерүчеләргә җитен җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен субсидияләү буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджетныкы булмаган чыганаклардан 27,5 миллион сум акча кирәк.

Татарстан Республикасында җитен чималын эшкәртү җитен заводында башкарыла. Әлеге предприятиедә эшкәртелә торган озын җепсел тукыма сәнәгате предприятиеләренә җибәрелә, кыска җепсел төзелеш тармагы предприятиеләренә җиткерелә. Җитен заводын үзгәртеп кору, техник һәм технологик яктан яңадан җиһазлау буенча чаралар әлеге предприятиедә, Европа стандартларына җавап бирә торган югары сыйфатлы озын җепсел, шулай ук җитеннән хәзерге вакытта аеруча зур ихтыяҗга ия булган яңа продукт ассортиментлары алып, җитен чималын тирән эшкәртү мөмкинлеген бирәчәк.

Җитен җепселен эшләп чыгаруны арттыру мәсьәләләре Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджетныкы булмаган чыганакларның акчалары хисабыннан субсидияләр бирү юлы белән хәл ителәчәк.

Үзгәртеп кору, техник һәм технологик яктан яңадан җиһазлау буенча чараларның һәм җитен җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен субсидияләү буенча сарыфларның гомуми бәясе 122,0 миллион сум тәшкил итә.

## 7. Программаны үтәү вакытлары

Программа чараларын 2015-2016 елларга исәпләнгән ике ел дәвамында үтәү каралган. Җитен тармагын төзү, үзгәртеп кору, техник яктан яңадан җиһазлау һәм модернизацияләү буенча чараларны үтәү проект документларында билгеләнгән.

Орлыклар һәм минерал ашламалар сатып алу буенча чаралар, сүсле җитен үстерү буенча эшләр сезонлы характерга ия, алар оптималь агротехник чорларда башкарылачак.

Программа 2015-2016 еллардагы чорда тормышка ашырыла.

### Программа чараларын тормышка ашыру графигы

| № п/п | Программа бүлекләре, чаралар | Үтәү өчен җаваплы | Башкару чорлары | Эшләр күләме |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Җитен тармагы өчен чыгымнар | Министрлык | 2015-2016 еллар | 122 млн сум |

## 8. Программаны үтәүнең социаль, икътисади нәтиҗәләренә тасвирлама, максатка ирешүдә Программа керткән өлешкә гомуми бәяләмә

Җитенчелек тармагын үстерү нәтиҗәле технологик чылбыр төзүгә юнәлдерелә: чимал җитештерү – беренчел эшкәртү – әзер продуктларны җитештерү. Бу сыйфатлы озын җепсел, азык-төлек һәм техник җитен маен һәм илкүләм икътисадындагы тукыма, азык-төлек, медицина, химия, фармацевтика, төзелеш тармаклары өчен ихтыяҗга ия булган яңа продукт төрләрен чыгаруны тәэмин итәчәк.

Шул рәвешле, җитен комплексын тотрыклы үстерү ышанычлы чимал базасын булдыру өлешендә икътисадның чиктәш тармакларын үстерүгә уңай йогынты ясаячак.

Моннан тыш, программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә яңа 15 эш урыны булдырылачак, бу тармакка яшь, югары квалификацияле кадрларны җәлеп итәргә ярдәм итәчәк, анысы авыл хуҗалыгы тармагында аеруча актуаль булып тора. Авыл хуҗалыгында җитештерүне һәм җитен чималын беренчел эшкәртүне уңышлы үстерү бөтен дәрәҗәдәге бюджетларга салым түләүләреннән булган финанс акчалары килүне арттырачак.

Программаны тормышка ашыру үзебезнең илдәге үсемлекчелек продуктларының көндәшлеккә сәләтен арттыруда булышачак, җитенчелекне тотрыклы үстерү һәм җитен җепселен җитештерү күләмнәрен арттыру өчен шартлар һәм керешеп китү мөмкинлекләрен булдырачак.

## 9. Бюджет акчаларын тотуның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаның максатчан индикаторлары динамикасын анализлау күрсәткәнчә, тулы күләмдә финанслану шарты белән программа чараларын гамәлгә ашыру җитештерү күләмнәрен сизелерлек күләмдә арттыруга китерәчәк.

Программаны үтәү еллары буенча аталган индикаторларның һәм финанслау күләмнәренең динамикасы 7 һәм 8 таблицаларда күрсәтелде:

**Программаны үтәү еллары буенча инднкаторлар динамикасы**

**7 таблица**

| Күрсәткечнең аталышы | Үлчәү берәм-леге | 2013 ел | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 ел өчен барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. Җитен җепселен тулай җыеп алу | мең тонна | 0,66 | 1,3 | 1,5 | 1,6 | 4,4 |
| 2. Сүсле җитен орлыгын тулай җыеп алу | мең тонна | 0,05 | 0,09 | 0,1 | 0,11 | 0,3 |
| 3. Сүсле җитен уңышы | ц/га | 13,2 | 13,5 | 13,6 | 13,7 | - |
| 4. Чәчүлек мәйданы | га | 500 | 860 | 1000 | 1100 | 2960 |
| 5. Җитен заводларында җитен җепселе эшкәртү | тонна | 630 | 1100 | 1320 | 1420 | 3840 |
| 6. Җитен җепселен сатудан алынган табыш | млн сум | 25,2 | 44,4 | 52,8 | 56,8 | 154 |
| 7. Табышның ел саен артуы | млн сум | - | 19,2 | 8,4 | 4 | 31,6 |
| 8. Табыш артымы | % | - | 176 | 119 | 107 | - |
| 9. Эш урыннары булдыру | кеше | - | 5 | 10 | 15 | 30 |

Программаны тормышка ашыру экология өчен тискәре нәтиҗәләргә китерми, ул игенчелек культураларын яхшырту буенча культуралы-техник чаралар башкару юлы белән төбәктәге табигый ресурсларны торгызуга һәм саклауга ярдәм итәчәк.

**Программаны үтәү еллары буенча финанслау күләмнәренең нәтиҗәлелек динамикасы**

**8 таблица**

| Күрсәткечнең аталышы | Үлчәү берәмлеге | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 3 ел өчен барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. Финанслау күләме | млн сум | 116,0 | 87,0 | 35,0 | 299,0 |
| 2. Җитен җепселен тулай җыеп алу | мең тонна | 1,3 | 1,5 | 1,6 | 4,4 |
| 3. Сүсле җитен орлыгын тулай җыеп алу | мең тонна | 0,09 | 0,1 | 0,11 | 0,3 |
| 4. Сүсле җитен уңышы | ц/га | 13,5 | 13,6 | 13,7 | - |
| 5. Чәчүлек мәйданы | га | 860 | 1000 | 1100 | 2960 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. Житен заводларында житен җепселе эшкәртү | тонна | 1100 | 1320 | 1420 | 3840 |
| 7. Житен җепселен сатудан алынган табыш | млн сум | 44,4 | 52,8 | 56,8 | 154 |
| 8.Нәтиҗәлелек күрсәткечләре, процентларда | % | 16,5 | 9,6 | 11,4 | 38,6 |

## 10. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан һәм бюджетныкы булмаган чыганаклардан акчалар җәлеп итеп гамәлгә ашырылачак.

Программа буенча планлаштырылган чараларны тормышка ашыру өчен таләп ителә торган акчаларның күләме орлык заводларын техник яктан җиһазлау буенча экспертлар тарафыннан бәяләнгән капиталь кертемнәрне исәпкә алып исәпләнә.

Программа чараларын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча исәпләмәләр һәм беренчел күрсәткечләр 9 таблицада китерелде.

**Программа чараларын финанслау өчен гомуми ихтыяҗ һәм аның чыганаклары, млн сум**

**9 таблица**

| Чараның аталышы | Финанслау чыганаклары | 2015 | 2016 | 2015-2016 елларда барлыгы |
|---|---|---|---|---|
| Житен тармагы өчен сарыфлар | Төбәк бюджеты | 20 | 3 | 23 |
| | Бюджетныкы булмаган чыганак | 67 | 32 | 99 |
| | Барлыгы: | 87 | 35 | 122 |
| Шул исәптән, үзгәртеп коруны, техник яктан яңадан җиһазлауны һәм модернизацияләүне исәпкә алып, капиталь чыгымнар | Төбәк бюджеты | 15 | - | 15 |
| | Бюджетныкы булмаган чыганак | 59,5 | 20 | 79,5 |
| | Барлыгы: | 74,5 | 20 | 94,5 |
| Шул исәптән, житен җитештерүгә чыгымнарның бер өлешен субсидияләү | Төбәк бюджеты | 5 | 3 | 8 |
| | Бюджетныкы булмаган чыганак | 7,5 | 12 | 19,5 |
| | Барлыгы: | 12,5 | 15 | 27,5 |

## 11. Программаның үтәлеше белән идарә итү системасын тасвирлау

Программа белән комплекслы идарә итүне һәм федераль һәм республика бюджетларыннан алынган акчалар белән эш итүне бюджетны

планлаштыру субъекты – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы хәл итә.

Программаның үтәлеше белән идарә итү системасы:

Программа үтәлеше өчен, программаның максатларына, бурычларына, максат индикаторларына, Программада расланган бурычларның һәм чараларның күрсәткечләренә ирешү өчен тулаем алганда Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге җаваплы булып тора;

Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы Министрлыкның структур бүлекчәләренең, Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы учреждениеләренең һәм оешмаларының эшчәнлеген координацияләү һәм Программа чараларын үтәү буенча аларның эшчәнлекләрен килештерү эшләрен Министрлыкның икътисади анализ һәм планлаштыру бүлеге белән игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башкара;

Программаның һәр чарасын үтәүне һәм, әлбәттә, программаны үтәүне Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге һәм кызыксынган бүлекләре гамәлгә ашыра;

Программа чараларын финанслауны Министрлыкның финанслау бүлеге хәл итә;

Программа үтәлешен мониторинглауны Министрлыкның түбәндәге бүлекләре гамәлгә ашыра: игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, икътисади анализ һәм планлаштыру бүлеге, агросәнәгать комплексының инженерлык-техник тәэминат бүлеге, кадрлар бүлеге, фән, мәгариф һәм инновацияле технологияләр бүлеге, азык-төлек базарын үстерү бүлеге, инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге, финанслау бүлеге, агросәнәгать комплексы предприятиеләрен реструктуризацияләү һәм агробизнесны үстерү бүлеге;

Программаны үтәү барышында хисапнамә формалаштыру өчен Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге, Министрлыкның икътисади анализ һәм планлаштыру бүлеге, Министрлыкның бухгалтерлык исәбе һәм хисапнамә бүлеге җаваплы.

Программа чараларын финанслар белән тәэмин итүдә федераль бюджетның һәм республика бюджетының чыгым йөкләмәләренә карата хокукый нигезләмәләре Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән төзелгән, соңгыларын Программада катнашучыларның санына кертү турындагы килешүне имзалау нәтиҗәсендә барлыкка килә.

## 12. Программаның үтәлеш куркынычларын бәяләү

Планлаштырылган нәтиҗәләргә ирешү өчен йогынты ясый алырга мөмкин булган төп куркынычларга түбәндәгеләр керә:

тышкы куркынычлар:

дәүләти-шәхси партнерлык линиясе буенча инвесторлар ягыннан, шулай ук авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре ягыннан үзләренең һәм

бурычка алынган акчалары хисабыннан финанслау дәрәҗәсенең җитәрлек күләмдә булмавы;

начар табигый-климат шартлары;

эчке куркынычлар:

җитештерүдәге һәм технологик куркынычлар.

Программаны үтәү кысаларында куркынычлар белән идарә итү аны барлык чыганаклардан үз вакытында төгәл һәм үз вакытында финанслау рәвешендә һәм технологик регламентларны тогәл үтәү рәвешендә үткәрелергә тиеш. Энергияйөрткечләргә, ашламаларга, башка товарларга һәм авыл өчен хезмәтләргә карата нигезсез дәрәҗәдәге югары бәяләргә бәйле булган куркынычлар федераль дәрәҗәдә дәүләт идарәлегенә тиешле.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
30.09.2015 № 228/2-пр боерыгына
(ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
10.02.2016 № 12/2-пр боерыгы
төзәтмәсендә) 2 кушымта

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын
үстерү” төбәк программасын үтәүдә катнашучы авыл хуҗалыгы товар
җитештерүчеләренә 2016 елда субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын (алга таба – Программа) тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (алга таба – Программада катнашучылар) субсидияләр бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр 2015 елның 20 ноябрендәге “2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында” № 90-ТРЗ Татарстан Республикасы Законында каралган бюджет ассигнованиеләре кысаларында һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) шушы Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.

3. Программада катаншучының милегендә һәм (яки) аренда шартларында җитен чәчелгән җир кишәрлекләре булу субсидияләр бирелүнең шарты булып тора.

4. Арбитраж суды тарафыннан Программада катнашучыга карата бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган очракта, алар (катнашучылар) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка язмача хәбәр итәргә бурычлы. Арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган Программада катнашучыларга субсидияләр бирелми.

5. Субсидияләрне бирү максаты җитенне җитештерү һәм эшкәртү күләмнәрен арттыру өчен икътисади һәм технологик шартларны тудырудан гыйбарәт.

6. Субсидия алу өчен Программада катнашучыларны сайлап алу критериесы булып авыл хуҗалыгында җитештерү эшчәнлеге торе буларак җитенне үстерү һәм (яки) беренчел эшкәртү буенча эшчәнлек башкару тора.

7. Субсидияләр Программада катнашучыларга түбәндәгеләр өчен бирелә:

а) җитенне беренчел эшкәртү буенча объектларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм модернизацияләүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, – Программаны үти башлаганнан соң бер елдан артык булмаган чорда

башкарылган эшләрнең күләменнән 28,6 проценты күләмендәге исәпләмәсеннән, шул исәптән федерал бюджеттан – 20 процент;

б) җитенне беренчел эшкәртү буенча технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга киткән чыгымнарның бер өлешен каплау буенча, – Программаны үти башлаганнан соң бер елдан артык булмаган чорда сатып алынган җайланманың бәясеннән 28,6 проценты күләмендәге исәпләмәсеннән, шул исәптән федераль бюджеттан – 20 процент;

в) җитенне җитештерүгә киткән чыгымнарның бер өлешен каплау буенча, – җитен эшкәртү заводына тапшырылган җитеннең (сүскә күчергәндә) бер тоннасы өчен 7436 сумнан исәпләгәндә, шул исәптән федераль бюджет акчалары хисабыннан – 5200 сум.

8. Шушы Тәртипнең 7 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

җитенне беренчел эшкәртү буенча объектны төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча җыелма смета исәпләмәсенең күчермәсе;

җитенне беренчел эшкәртү буенча объектны төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү буенча подряд шартнамәсенең күчермәсе;

№КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” статистика рәвешләре буенча белешмә;

№КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмә” статистика рәвеше буенча белешмә;

№КС-2 “Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт” һәм №КС-3 “Башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмә” статистика рәвешләре буенча белешмәләр, – эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда;

башкарылган эшләр өчен түләгәнлекне раслый торган, банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәсе;

Министрлык тарафыннан расланган рәвештә субсидияләрне бирү өчен белешмә-исәпләмәләр.

Тапшырылган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

9. Шушы Тәртипнең 7 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы китерүгә шартнамәләрнең күчермәләре;

товар-транспорт кәгазьләре;

№ ОС-1 рәвешендә җайланманы кабул итү-тапшыру турында акт;

житенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы өчен түләгәнлекне раслый торган, банк тарафыннан таныкланган түләү йөкләмәләре;

Министрлык тарафыннан расланган рәвештә субсидияләрне бирү өчен белешмә-исәпләмәләр.

Тапшырылган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

10. Шушы Тәртипнең 7 пунктындагы "в" пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Программада катнашучылар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

ирекле рәвештә, үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирелү турында гариза;

талкынмаган җитен китертүгә шартнамәләр;

кабул итү квитанцияләре;

Министрлык тарафыннан расланган рәвештә субсидияләрне бирү өчен белешмә-исәпләмәләр.

Тапшырылган документларның күчермәләре Программада катнашучылар тарафыннан таныклана.

11. Министрлык:

субсидияләр бирелү турында гаризаны кергән көненнән соң бер көн эчендә дәфтәрдә терки, ул номерланырга, тегелергә һәм Министрлык мөһере белән беркетелергә тиеш;

гаризаны теркәгәннән соң 20 көнлек чорда тапшырылган документларны шушы Тәртипнең 8-10 пунктлары нигезендә тикшерә һәм субсидияне бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

12. Субсидияләр бюджет акчалары кысаларында гаризалар тапшырылу тәртибендә бирелә.

Субсидияне бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

документларны тулы күләмдә тапшырмау яки аларның шушы Тәртип таләпләренә җавап бирмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитында калдык өлеш булмау.

Субсидияләрне бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык 11 пунктның өченче кызыл юлында күрсәтелгән чор узганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек чорда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә баш тарту турында белдерүнамә җибәрә.

Субсидия бирүдән баш тарту законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

13. Министрлык Программада катнашучылар белән Министрлык тарафыннан раслана торган рәвештә Субсидияләр бирелү турында килешү (алга таба – Килешү) төзи, анда субсидия алучыларның Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан субсидияләрне алучылар тарафыннан аларны бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүен тикшерүгә ризалык бирүе субсидия бирелүнең мәҗбүри шарты булып тора.

14. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментында ачылган лицевой счетларыннан Программада катнашучыларның исәп-хисап счетларына, субсидияләрне бирү өчен Министрлык тарафыннан расланган белешмә-исәпләмәләр нигезендә, шушы Тәртипнең 11 пунктындагы өченче кызыл юлда күрсәтелгән вакыт узганнан соң ункөнлек чорда акча чараларын күчерә.

15. Бирелгән субсидияләр, бу Тәртиптә билгеләнгәнчә, аларны бирү максатларын һәм шартларын бозу, субсидияләрне максатчан файдаланмау яки субсидияләр алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда, Министрлык таләбе алынганнан соң 60 көн эчендә федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

16. Субсидияләр алу турында килешүләрдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр калдыклары субсидияләр алучылар тарафыннан, субсидияләр бирелгән елдан соң килгән елның 1 декабренә кадәр, федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш.

17. Бу Тәртипнең 15 һәм 16 пунктларында күрсәтелгән бюджет акчаларын федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты керемено ихтыярый рәвештә кире кайтарудан баш тарту очрагында, алар, закон нигезендә, мәҗбүри тәртиптә түләтелергә тиеш.

18. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

19. Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларның җитәкчеләренә һәм вазифаи затларына йөкләнә.

20. Бюджет акчаларыннан максатчан файдалануга Министрлык контрольлек итә.

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
30.09.2015 № 228/2-пр боерыгына
(ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
10.02.2016 № 12/2-пр боерыгы
төзәтмәсендә) 3 кушымта

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирелү турында
КИЛЕШҮ №_______

Казан ш. “_____”_______________2016

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, алга таба “Министрлык” дип исемләнә, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр Әхмәтов Марат Готыф улы исеменнән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәсьәләләре” № 316 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә гамәл кылучы, бер яктан, һәм ____________________ ____________________________________________________________________,
(субсидия алучының аталышы, ИНН)
алга таба “Алучы” дип исемләнә, ______________________________ исеменнән,
(Ф.И.А.)
______________________________________нигезендә гамәл кылучы, икенче яктан, икесе бергә “Тарафлар” дип аталучылар, 2015 елның 14 декабрендәге “2016 елга федераль бюджет турында” № 359-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон) һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 14 июлендәге № 717 карары белән расланган 2013-2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктларының, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салуның дәүләт программасы (алга таба – Дәүләт программасы) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 08 апрелендәге № 235 карары белән расланган “2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продуктларының, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу” Татарстан Республикасы дәүләт программасын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге “Россия Федерациясе субъектларының авыл хуҗалыкларын үстерү буенча икътисади әһәмиятле булган төбәк программаларына теләктәшлек күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бүлү һәм бирү кагыйдәләрен раслау турында” № 1042 карары (алга таба – Кагыйдәләр), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016

елның 14 мартындагы “2016 елда агросәнәгать комплексына дәүләтнең ярдәм чаралары турында” № 138 карары нигезендә түбәндәгеләр хакында әлеге Килешүне (алга таба – Килешү) төзеде:

## 1. Килешү предметы

1.1. Министрлык әлеге Килешү һәм Министрлык боерыгы нигезендә расланган Ведомстводның максатчан икътисади әһәмиятле “2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын (алга таба – Программа) тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә җитенне беренчел эшкәртү буенча объектны төзү, үзгәртеп кору һәм модернизацияләү өчен; җитенне беренчел эшкәртү объектлары өчен технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу өчен; җитен җитештерү өчен тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга Алучыга субсидия бирү бурычын үз өстенә ала.

1.2. Килешүдә каралмаган юнәлешләр буенча чыгымнарны финанслау рөхсәт ителми.

## 2. Тарафларның хокуклары

**2.1. Министрлык түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.1.1. Алучыдан Килешүне үтәү өчен кирәкле булган мәгълүматны, белешмәләрне һәм документларны соратырга;

2.1.2. Законнарда билгеләнгән тәртиптә Алучы тарафыннан субсидияләр бирелүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерергә.

**2.2. Алучы түбәндәгеләргә хокуклы:**

2.2.1. Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәмен алырга. Субсидияләр законнарда билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре лимитлары кысаларында бирелә;

2.2.2. Консультатив һәм мәгълүмати ярдәм алуга.

## 3. Тарафларның бурычлары

Министрлык белән Алучы әлеге Килешүнең тулы күләмдә үтәлешенә ярдәм итү бурычын үз өсләренә ала, Килешүне үтәүгә комачаулык итә торган хәлләр барлыкка килгән очракта, тарафлар бер-берсенә бу хакта хәбәр итешеп торачак һәм аны үтәү буенча килештерелгән гамәлләр кылачак.

**3.1. Министрлык бурычлары:**

3.1.1. Законнарда билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә, билгеләнгән лимитлар кысаларында, Алучының исәп-хисап счетына субсидияләрне күчерү;

3.1.2. Алучы тарафыннан шушы Килешүдә каралган шартлар үтәлмәгәндә, аңа субсидия күчерүне туктату яки субсидияләрнең зурлыгын (күләмен) киметү (кыскарту).

3.1.3. Алучы тарафыннан субсидияләрне алу өчен тапшырылган документларны тикшерү.

3.1.4. Алучыны Килешү буенча Алучының бурычларын үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә консультацияләү.

3.1.5. Алучы тарафыннан законнарда субсидияләрне бирү өчен билгеләнгән шартлар бозылганда, алынган субсидияләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә кайтарып бирелүен таләп итү.

**3.2. Алучының бурычлары:**

3.2.1. Законнарда билгеләнгән вакытта, тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән, субсидияләрне алу өчен Министрлыкка документлар җыелмасын тапшыру.

3.2.2. Министрлыкка язмача рәвештә түбәндәгеләр хакында хәбәр итү:

Алучының бетерелүе яки үзгәртеп корылуы турында, – карар кабул ителгән көннән башлап өч эш көненнән артык булмаган чорда;

2002 елның 26 октябрендәге "Бөлгенлек (банкротлык) турында" № 127-ФЗ Федераль законда каралган бөлгенлек турындагы эштә кулланыла торган процедуралар кертелү хакында, – арбитраж суды тарафыннан билгеләмә чыгарылган датадан соң өч эш көненнән артмаган чорда.

3.2.3. Министрлык һәм дәүләт (муниципаль) финанс контрольлеге органнары тарафыннан Алучының субсидияләрдән максатчан файдалану кагыйдәләрен үтәвен тикшерүгә ризалык бирү.

3.2.4. Субсидияләрне бирү өчен законнарда билгеләнгән барлык шартларны тиешле тәртиптә үтәү.

## 4. Суммаларны кайтарып бирү тәртибе

4.1. Башкарма хакимият органнары яки бүтән вәкаләтле дәүләт контрольлек һәм күзәтчелек органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерү барышында һәм тиешле Тәртип (кагыйдәләр) һәм әлеге Килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирелү максатлары һәм шартлары бозылу очраклары ачыкланганда яки субсидияләрне алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар, хисаплар тапшырылганда, Алучы бирелгән субсидияләрне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары кеременә, Алучының үзе тарафыннан әлеге очрак ачыклану датасыннан соң яки Министрлыктан акча чараларын кайтарып бирү таләбе алынган көннән соң алтмыш көнлек чорда кайтарып бирергә бурычлы.

4.2. Аталган акчаларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары керемена ирекле кайтарып бирүдән баш тарткан очракта, алар мәҗбүри тәртиптә законнар нигезендә түләттерелергә тиешле була.

4.3. Тарафларның уртак килешүе буенча һәм Алучы тарафыннан субсидияләр кайтарып бирелгән очракта Килешү ирекле нигездә тарткатыла.

## 5. Тарафларның җаваплылыгы

5.1. Бирелгән лимитларның чикләрендә субсидияләрне максатчан һәм үз вакытында күчерү өчен Министрлык җаваплы була.

5.2. Субсидияләрдән нәтиҗәле файдалану, Министрлыкка тапшырыла торган документларның, белешмәләрнең һәм хисапларның дөреслеге, тулылыгы һәм үз вакытында тапшырылуы өчен, шулай ук шушы Килешүдә һәм законнарда билгеләнгән шартларның үтәлеше өчен Алучы җаваплы була.

5.3. Субсидияләрне бирү һәм бүлү тәртипләре нигезендә Алучы кредитлардан максатчан файдаланган өчен җаваплы була. Үтәлмәгәндә Алучы бирелгән субсидияләрне Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетлары керемнә әлеге очрак ачыклану датасыннан соң яки Министрлыктан акча чараларын кайтарып бирү таләбе алынган көннән соң алтмыш көнлек чорда кайтарып бирергә бурычлы.

5.4. Шушы Килешү буенча үзенең бурычлары үтәлмәгәндә яисә тиешенчә үтәлмәгәндә, Тарафлар законнар һәм шушы Килешү шартлары нигезендә җаваплы булалар.

5.5. Форс-мажор хәлләре барлыкка килгәндә, законнарда Килешү йөкләмәләрен үтәү өчен каршылык тудыра торган тыюлы яки чикләмәле чаралар кертелгәндә, Тарафлар Килешүне үтәмәгән өчен җаваплы булудан азат ителә. Югарыда саналган хәлләр барлыкка килгәндә, Тарафлар сөйләшүләр алып бара һәм Шартнамә шартларына үзгәрешләр кертә.

## 6. Бәхәсләрне хәл итү

6.1. Шушы Килешүдән барлыкка килә торган бәхәсләрне һәм ризасызлыкларны хәл итү буенча Тарафлар сөйләшүләр алып бару юлы белән барлык чараларны да күрәләр.

6.2. Килешүдән барлыкка килә торган Тарафларның барлык бәхәсләре һәм ризасызлыклары, әгәр дә сөйләшүләр алып бару юлы белән хәл ителмәсә, законнарда билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

## 7. Бүтән шартлар

7.1. Бу Килешүгә карата барлык үзгәрешләр, өстәмәләр һәм кушымталар язмача рәвештә өстәмә Килешү белән рәсмиләштерелә һәм һәр Тарафның шуңа вәкаләт бирелгән затлары тарафыннан имзалана, ул аның аерылгысыз өлеше булып тора.

7.2. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде, һәркайсы тигез юридик көчкә ия, Тарафларның һәркайсы өчен берәр нөсхәдә.

7.3. Әлеге Килешү Тарафларның һәркайсыннан шуңа вәкаләтләнгән затлар имза салгач һәм агымдагы финанс елы тәмамланганчыга кадәр гамәлдә була.

## 8. Тарафларның урнашкан урыннары (дәүләт теркәвенә алынган) адреслары һәм реквизитлары:

Министрлык:
Татарстан Республикасының
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгы

420014, Россия, Татарстан
Республикасы, Казан ш.,
Федосеевская ур., 36 й.

р/сч:40101810800000010001
ОТДЕЛЕНИЕ-НБ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
г. КАЗАНЬ

УФК по Республике Татарстан
(Министерство сельского хозяйства
и продовольствия Республики
Татарстан, 04112001090)
ИНН 1654019555
КПП 165501001
ОГРН 1021602854580

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
Татарстан Республикасының
авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министры

__________________М.Г. Әхмәтов

Алучы:
________________________
________________________
________________________

Урнашкан урыны:
________________________
________________________

ИНН__________________
р/сч
________________________
________________________
(банк аталышы)

БИК___________________
к/с_____________________

__________ __________________
(имза) (Ф.И.А.)
булган очракта
мөһер

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
30.09.2015 № 228/2-пр боерыгына
(ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
10.02.2016 № 12/2-пр боерыгы
төзәтмәсендә) 4 кушымта

____________________________________________________________ буенча
(субсидия алучының аталышы, муниципаль район аталышы)

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен
комплексын үстерү” төбәк программасын тормышка ашыруда
катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян
(фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләргә федераль
бюджет акчалары хисабыннан тиешле субсидия турында
белешмә-исәпләмә

| Программаны үти башлаганнан бирле тотылган чыгымнарның күләме | Чыгымнар суммасы, сумнарда | Субсидия ставкасы | Субсидия суммасы, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү һәм үзгәртеп кору | | Тотылган чыгымнарның 20 проценты | |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларына технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу | | Тотылган чыгымнарның 20 проценты | |
| Җәмгысе: | | X | |
| Продуктның аталышы | Җитештерү күләме, тонна | Субсидия ставкасы, сумнарда | Субсидия суммасы, сумнарда |
| Талкынмаган җитен (сүскә күчергәндә) | | 5200 | |
| Барлыгы: | X | X | |

ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
30.09.2015 № 228/2-пр боерыгына
(ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгының
10.02.2016 № 12/2-пр боерыгы
төзәтмәсендә) 5 кушымта

_______________________________________________ буенча
(субсидия алучының аталышы, муниципаль район аталышы)

Ведомствоның максатчан икътисади әһәмиятле
“2015-2016 елларга Татарстан Республикасында җитен комплексын үстерү” төбәк программасын тормышка ашыруда катнашучы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабыннан тиешле субсидия турында белешмә-исәпләмә

| Программаны үти башлаганнан бирле тотылган чыгымнарның күләме | Чыгымнар суммасы, сумнарда | Субсидия ставкасы | Субсидия суммасы, сумнарда |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларын төзү һәм үзгәртеп кору | | Тотылган чыгымнарның 8,6 проценты | |
| Җитенне беренчел эшкәртү объектларына технологик җайланма, автотранспорт һәм авыл хуҗалыгы техникасы сатып алу | | Тотылган чыгымнарның 8,6 проценты | |
| Җәмгысе: | | Х | |
| Продуктның аталышы | Җитештерү күләме, тонна | Субсидия ставкасы, сумнарда | Субсидия суммасы, сумнарда |
| Талкынмаган җитен (сүскә күчергәндә) | | 2 236 | |
| Барлыгы: | Х | Х | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
_________________________
муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе башлыгы ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(мөһер) ________ ____________________
(имза) (Ф.И.А.)

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык төлек
министры ________________________М.Г. Әхмәтов
(мөһер) (имза)

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйм:
Субсидия алучы оешманың җитәкчесе ________ ________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(булган очракта) ________ ________________
(имза) (Ф.И.А.)

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
________________________
муниципаль районындагы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе башлыгы ________ ________________
(имза) (Ф.И.А.)

Баш бухгалтер
(мөһер) ________ ________________
(имза) (Ф.И.А.)

ТР Премьер-министры урынбасары –
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык төлек
министры ________________________М.Г. Әхмәтов
(мөһер) (имза)

# Л И С Т   С О Г Л А С О В А Н И Я

Проекта приказа

1. Наименование документа: Проект приказа «О внесении изменений в приказ Минсельхозпрода РТ от 30.09.2015 №228/2-пр».

2. Проект подготовлен Отделом инвестиционной политики и целевых программ Министерства сельского хозяйства и продовольствия Республики Татарстан

(наименование подразделения, организации)

Начальник отдела инвестиционной политики и целевых программ; Гафуров И.Ш. , тел.221-76-28

(должность, ФИО исполнителя, телефон)

Визы согласования:

| Наименование, подразделения, организации, должность | Фамилия, имя, отчество | Дата передачи на согласование | Подпись, дата согласования. Краткое содержание Замечания | Замечание устранено Подпись, дата |
|---|---|---|---|---|
| Первый заместитель министра | Н.Л.Титов | | | |
| Заместитель министра | И.Х.Габдрахманов | | | |
| Начальник отдела инвестиционной политики и целевых программ | И.Ш.Гафуров | | | |
| Начальник отдела финансирования | М.А.Махмутов | | | |
| Начальник отдела развития отраслей земледелия | В.Л.Новичков | | | |
| Начальник юридического отдела | Р.Г.Фассахова | | | |
| Начальник отдела делопроизводства и контроля | Р.К.Багаутдинова | | | |

Передано на доработку ________________________________________

Передано на подпись __________________________________________

(дата, виза общего отдела)